| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга дәүләт ярдәмен күрсәтүне арттыру өчен **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-828 номерлы Указының 2 пунктына (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 23 июлендәге ПУ-494 номерлы, 2009 елның 27 февралендәге ПУ-106 номерлы һәм 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы, 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-876 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) икенче абзацта «25 мең сум» сүзләрен «50 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «биш мең сум» сүзләрен «10 мең сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм аның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 14 март
№ ПУ-232